MAHAD SUNNAH

# Намаз вакытында булган вәсвәсәләрне җиңү

# التغلب على وساوس الصلاة

## اللغة التترية

ALSARHAAN.COM

كثيرا ما ينتاب المسلم في صلاته او خارجها بعض من الخواطر القبيحة والوساوس السيئة.

Күп мөселманнарны намазларында яки намаздан тыш булган вакытларында төрле начар уйлар һәм яман вәсвәсәләр чолгап ала.

ولا ريب ان ذلك ومثله يكون من الشيطان. فهو حريص على اضلال المسلم وحرمانه من الخير وابعاده عنه.

Һәм бу вәсвәсәләрнең шәйтаннан булуына бер шик тә юк. Һәм шәйтан мөселманны адаштырырга, хәерлелектән мәхрүм итеп нигъмәтлерне юк итергә бик тырыша.

ومن رحمة الله تعالى أن العبد لا يؤاخذ بتلك الوساوس؛ ما لم يتكلم بها أو يعمل.

Ләкин Адәм баласы әйтмәгән яки эшләмәгән вәсвәсәләре өчен җавапка тартылмавы Аллаһның рәхмәтеннән булып тора.

قال النبي صلى الله عليه وسلم : إن الله تجاوز لأمتي عما وسوست، أو حدثت به انفسها ما لم تعمل به
او

**Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Чынлыкта, Аллаһ минем өммәтемә аларның күңелендә булган нәрсәләрне сөйли башланчы, я инде гамәлгә ашыра башлаганчыга кадәр гафу итәр».**

وقد يأتي الشيطان ويوسوس بأشياء منكرة في حق الله تعالى أو رسوله أو شريعته
يكرهها المسلم ولا يرضاها.

**Һәм шәйтан килеп Аллаһның яки Аның илчесенең яки шәригатьнең хаклары турында мөселманның күңелен шелтәле нәрсәләр белән вәсвәсәләндерә, хәтта шуның сәбәпле бу мөселман аларга карата нәфрәт хисе кичереп, алардан риза булмый башлый.**

وفراره من ذلك وكراهيته له دليل على صحة الايمان.
Һәм бу вәсвәсәләрдән арыну һәм аларга карата нәфрәт хисен тою – иманның сәламәт булуына дәлил булып тора.

فقد جاء ناس من أصحاب النبي صلى الله عليه وسلم : فسألوه أنا نجد في أنفسنا ما يتعاظم أحدنا أن يتكلم به.

Пәйгамбәребезгә ﷺ сәхәбәләреннән булган кешеләр килеп: "Чынлыкта, без күңелләребездә беребез әйтергә дә курыккан нәрсәләр табабыз",- дип хәбәр иттеләр.

قال وقد وجدتموه؟ قالوا نعم. قال ذاك صريح الايمان.

Пәйгамбәребез ﷺ алардан: "Сез аны таптыгызмы?,- дип сорады.
Алар: "Әйе", - дип җавап бирделәр.
Пәйгамбәребез ﷺ: "Бу чын иман", - дип әйтте.

والمسلم مأمور بمدافعة تلك الوساوس فإذا ما تهاون فيها واسترسل معها فإنه يؤاخذ بهذا التهاون.
Һәм мөселманга шушы вәсвәсәләрдән арынырга әмер ителгән. Әгәр ул аларга игътибар итмичә, килгән вәсвәсәләргә ирек бирсә, шуның өчен ул җавапка тартылачак.

وتدفع تلك الوساوس بأمور.
منها المداومة على قراءة القرآن والأذكار الشرعية صباحا ومساء.
Шушы вәсвәсәләрдән саклану төрләре:

– Иртә-кичен Коръән укуда, шәригатьтә килгән иртәнге һәм кичке зекерләр әйтүдә дәвамлы булу.

تقوية الايمان طاعات والبعد عن المنكرات.
– Иманны буйсыну аша һәм тыелган нәрсәләрдән ерагаю аша куәтләндерү.

الاشتغال بطلب العلم فإن العالم أشد على الشيطان من العابد.

– Гыйлем алу белән шөгыльләнү, чынлыкта, шәйтан өчен белемле кеше гыйбадәт кылган кешегә карата куркынычрак.

ومما تدفع به كذلك قول آمنت بالله ورسله.

Һәм шулай ук шәйтанның вәсвәсеннән саклanудан – Мин Аллаһка һәм Аның илчесенә иман китердем,- дип әйтү.

فعن عائشة رضي الله عنها: أن رسول الله صلى الله وسلم قال :
إن أحدكم يأتيه الشيطان فيقول من خلقك؟

Гаишәдән, Аллаһ аннан разый булсын, хәбәр итеlә: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Бер кешегә шәйтан килеп: "Сине кем барлыкка китерде",- дип сорар.

فيقول: الله.

Һәм ул: "Аллаһ", - дип әйтер.

فيقول: فمن خلق الله؟

Шуннан соң шәйтан әйтер: "Ә кем Аллаһны барлыкка китерде?, - дип.

فاذا وجد ذلك أحدُكم فليقرأ :

Пәйгамбәребез ﷺ дәвам итеп: "Һәм кем дә кем сездән моңа бирелсә, шушы сүзләрне әйтсен –

آمنت بالله ورسله. فإن ذلك يذهب عنه.

"Мин Аллаһка һәм Аның илчесенә иман китердем". Һәм шушы сүзләр бу шәйтанны куып җибәрер".

فإذا كانت الوسوسة في الصلاة فإنه يستعيذ بالله من الشيطان؛

Әгәр вәсвәсә намаз укыган вакытта булса, ул Аллаһка шәйтаннан сыенсын.

ويُتفل عن يساره ثلاثة.

Һәм өч тапкыр сулга таба төкереп куйсын.

فقد جاء رجل النبي صلى الله عليه وسلم

Бер кеше Пәйгамбәребезгә ﷺ килеп: "

فقال :

يا رسول الله :إن الشيطان قد حال بيني وبين وقراءتي يَلبِسها علي.

"Әй Аллаһның илчесе, хакыйкатьтә, шәйтан миңа, минем намазыма һәм укуыма комачаулый һәм мине томаландыра",- дип әйтте.

فقال رسول الله صلى الله عليه وسلم: ذاك شيطان يقال له خنزب.

Пәйгамбәребез ﷺ "Бу бит шәйтан, аңа шулай ук иблис дип әйтәләр.

فإذا أحسسته فتعوذ بالله منه.

Әгәр син аны сизсәң, аннан Аллаһка сыен.

فإذا أحسسته فتعوذ بالله منه.

Әгәр син аны сизсәң, аннан Аллаһка сыен.

واتفل على يسارك ثلاثا.

Һәм өч тапкыр сул ягыңа төкереп куй", - дип әйтте.

قال : ففعلت ذلك فاذهبه الله عني

Күпмедер вакыттан соң бу кеше: "Мин шулай эшләдем һәм Аллаһ шәйтанны миннән ерагайтты",- дип хәбәр итте".